**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2020 елның «4» июненнән № 61-381

Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 24.10.2009 ел, 53-325 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмә"гә үзгәрешләр кертү хакында"

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына казначылык хезмәте күрсәтү һәм казначылык түләүләре өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 479-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда РФ бюджет системасы бюджетлары үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү турында " 2020 елның 1 апрелендәге 103-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 24.10.2009 ел, №53-325 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмә» гә (алга таба Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1 бүлегендә«Район бюджеты дефициты» турындагы 15 статьяның 2 пунктындагы 3 абзацында «акчаларны исәпкә алу буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. Нигезләмәнең IV бүлегендәге «Бюджетны үтәү нигезләре» турындагы 48 статьяның 3 пунктындагы 3 абзацында "касса" сүзен "казначылык" сүзенә алмаштырырга;

1.3. Нигезләмәнең IV бүлегендәге "Чыгымнар буенча район бюджеты үтәлеше" турындагы 52 статьясындагы 3 пунктында «түләүле» сүзләрен «казначылык түләүләрен башкару турында күрсәтмәләр (алга таба-күрсәтмәләр)" сүзләренә алмаштырырга;

1.4. Нигезләмәнең IV бүлегендәге «чыгымнар буенча район бюджеты үтәлеше» турындагы 52 статьясындагы 4 пунктында «түләү документлары» сүзләрен «күрсәтмәләр» сүзләренә алмаштырырга.

2. Нигезләмәнең түбәндәге пунктларын 2021 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булуын туктатып торырга:

10 статьядагы 2 пункт, 45 статьядагы 1 пункт, 55 статьядагы 1 пункт, 58 статьядагы 3 пункт, 59 статьядагы 1 пункт.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына район бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http//pravo.tatarstan.ru , Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В.М. Козлов